**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 255**
**21.07.2020**

Шәһәр Хакименең 2011 елның 11 мартындагы 150 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, сугыш кирәк-яракларының һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнештә йөрүен кисәтү чаралары турында» 1995 елның 5 августындагы 545 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 апрелендәге 255 номерлы карары, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе турында» 2011 елның 11 мартындагы 150 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«5) Яр Чаллы муниципаль берәмлеге территориясендә коралның, сугыш припасларының, коралга патроннарның, шартлаучан матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү буенча эшне оештыру.»;

2) 7 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктчаны өстәргә:

«7) законсыз саклана торган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен стимуллаштыручы акчалата бүләк бирү мөмкинлеген билгеләү максатында гражданнардан кергән документларны карап тикшерә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев